КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 ел, 19 март г.Казань № 194

Аерым түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтү вәкаләтләре Россия Федерациясе тарафыннан Татарстан Республикасына тапшырылган әлеге түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен һәм, аларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ветераннар турында» һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» федераль законнар белән билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне Россия Федерациясе субъектлары арасында бүлү методикасын раслау турында» 2006 ел, 27 март, 169 нчы; «Гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм Байконур шәһәре бюджеты арасында бүлү методикасын һәм Гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм Байконур шәһәре бюджеты арасында бүлү һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының һәм Байконур шәһәре бюджетының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып әлеге субвенцияләр торган чыгымнарын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында»

2007 ел, 12 декабрь, 861 нче; «Хәрби хезмәткә алу буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә алу буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие түләү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү тәртибе турында» 2009 ел, 4 февраль, 97 нче карары; «Россиянең мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга ел саен акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен башкару өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү турында» 2013 ел, 9 март, 197 нче; «Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында, вакытлыча эшкә сәләтсезлек очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләнергә тиеш булмаган затларга, шулай ук оешмаларны бетерүгә (физик затлар тарафыннан эшчәнлек, вәкаләтләр туктатылуга) бәйле рәвештә эштән азат ителгән затларга дәүләт пособиеләренең аерым төрләрен түләү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына бирелә торган субвенцияләрне бирү тәртибе турында» 2013 ел, 8 октябрь, 893 нче; «Радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү турында» 2014 ел, 24 декабрь, 1475 нче; «Беренче бала тууга (аны уллыкка алуга) бәйле рәвештә, айлык түләү билгеләү һәм аны гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен башкару өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр бирү турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1704 нче карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Аерым түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтү вәкаләтләре Россия Федерациясе тарафыннан Татарстан Республикасына тапшырылган әлеге түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен һәм, аларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

3.Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 19 март, 194 нче
карары белән расланды

Аерым түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтү вәкаләтләре
Россия Федерациясе тарафыннан Татарстан Республикасына тапшырылган
әлеге түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен һәм, аларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетына
федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне тоту
кагыйдәләре

1. Бу Аерым түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтү вәкаләтләре Россия Федерациясе тарафыннан Татарстан Республикасына тапшырылган әлеге түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен һәм, аларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) аерым түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтү вәкаләтләре Россия Федерациясе тарафыннан Татарстан Республикасына тапшырылган әлеге түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен һәм, аларны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләрне тоту юнәлешләрен билгели.

2. Кагыйдәләр түбәндәгеләр нигезендә Татарстан Республикасына тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда кулланыла:

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 ел, 15 май, 1244-1 нче Россия Федерациясе Законы;

«Ветераннар турында» 1995 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-5 нче Федераль закон;

«Балалары булган гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 ел, 19 май, ФЗ-81 нче Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон;

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны агызу аркасында радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 ел, 26 ноябрь, ФЗ-175 нче Федераль закон;

«Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 ел, 10 гыйнвар, ФЗ-2 нче Федераль закон;

«Кан донорлыгы һәм аның компонентлары турында» 2012 ел, 20 июль, ФЗ-125 нче Федераль закон;

«Балалары булган гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 ел, 28 декабрь, ФЗ-418 нче Федераль закон.

3. Бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән федераль законнарда беркетелгән һәм Россия Федерациясенең Татарстан Республикасына тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тора.

4. Бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән федераль законнар белән Татарстан Республикасына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашучы вәкаләтле орган карамагындагы дәүләт учреждениесе булып «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – дәүләт учреждениесе) тора.

5. Вәкаләтле орган һәм дәүләт учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләүгә юнәлдерелгән акча күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Hi = 1{,}5\%Si – Ri,$$

монда:

Hi – Россия Федерациясенең Татарстан Республикасына тапшырылган i-вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, вәкаләтле органның һәм дәүләт учреждениесенең эшчәнлеген тәэмин итү өчен чыгымнар күләме;

Si – Россия Федерациясенең Татарстан Республикасына тапшырылган i-вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр күләме;

Ri – аерым түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтү вәкаләтләре Россия Федерациясе тарафыннан Татарстан Республикасына тапшырылган әлеге түләүләрне илтеп бирү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча чыгымнар күләме.

6. Вәкаләтле органның һәм дәүләт учреждениесенең эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләүгә юнәлдерелә торган акча түбәндәге формула буенча бүленә:

$$Hi = Zi + Ci + Fi + Gi + Ti + Yi,$$

монда:

Hi – Россия Федерациясенең Татарстан Республикасына тапшырылган i-вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, вәкаләтле органның һәм дәүләт учреждениесенең эшчәнлеген тәэмин итү өчен чыгымнар күләме;

Zi – бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән федераль законнар белән Татарстан Республикасына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучы вәкаләтле орган һәм дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең эш хакын түләү һәм хезмәте өчен түләүне

башкаруга исәпләүләр өчен чыгымнар күләме, шул ук вакытта Zi Hi-нең 50 процентыннан артып китә алмый;

Ci – элемтә хезмәтләре өчен түләү чыгымнары күләме;

Fi – коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары күләме;

Gi – мөлкәтне карап тоту буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнары күләме;

Ti – матди запаслар кыйммәтен арттыру чыгымнары күләме;

Yi – башка чыгымнар өчен түләү чыгымнары күләме.

«Ветераннар турында» һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» федераль законнар белән билгеләнгән, гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча вәкаләтле органның эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләүгә юнәлдерелә торган акча күләме агымдагы елның IV кварталына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән Татарстан Республикасы буенча торакның гомуми мәйданының 1 кв.метрының уртача базар кыйммәтеннән чыгып исәпләнгән торак сатып алуга субсидия күләменнән артып китә яки аңа тигез була алмый.

___________________________